**Сеңлем Гөлнәзирә белән Кәрим кияүгә**

Башлы-күзле булу,

Кияү-кәләш

Ир һәм хатын булган сәгатьтер.

Юк аларга бүген җирдә тиңдәш,

Башлар күккә тигән халәттер.

Ир баш була белсен,

Хатын – муен!

Борынгылар сүзе -

Уйлыйм да

И, мин әйтәм, Ходай ярдәм бирсен

Башны ипле тоткан муенга.

Алай-болай муен – чуен булып,

Баш – таш кына була күрмәсен,

Антын бозып, баш иманын җиңеп,

Чит-ят “муен” эзләп йөрмәсен!

Сер түгел бит:

Хокук тигез диеп

Баш урынын даулый муен да,

Характерлар килешмәүгә өеп

Аерылулар соңгы модада.

Күпме гаилә пыран-заран килә

Күпме бала үсә атасыз...

...И, туганнар! Чын мәхәббәт белән

Яшәсәгез иде хатасыз!

Инә күзләреннән дөя шәйләп

Суытмагыз сөю җылысын!

Арагызда иблис гайбәт түгел,

Нәни генә сабый җылынсын!

Берәү генә түгел, икәү, өчәү...

Планнан тыш тагын, тагын да.

Курыкмагыз бәби багулардан

Әбекәйләр хәлле чагында!

Тормыш уен түгел,

Тик, шулай да,

Уйнап-көлеп яшәү күңелле!

Олыларча әйтсәк – бирсен Ходай

Сезгә тигез, озын гомерне!